**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 25-9 16 февраль 2016 ел

Туйкә авылы җирлеге биләмәсендә
үзарасалым җыю һәм куллану
буенча җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Туйкә авыл җирлеге Уставының 12 маддәсе, Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 29 январь 2016 елда чыккан 5 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Туйкә авыл җирлеге Советының 29 январь 2016 елда чыккан 24-8 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча 17 апрель 2016 ел көнне референдум үткәрергә.

2. Референдумда караласы мәсьәлә:

"Сез, Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә үзарасалым җыю белән килешәсезме. Үзарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, игътибар үзәгендә тоту (асфальт юлларны ремонтлау)- 40 мең сум;

2) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, игътибар үзәгендә тоту (юлларга таш ташытып, җәйдерү)- 26 мең сум;

3) ял вакытын оештыру өчен шартлар тудыру һәм җирлек халкына мәдәни оешмалар хезмәте күрсәтүне тәэмин итү (бәйрәмнәр оештыру)- 16 мең сум;

4) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны оештыру) - 20,5 мең сум.

ӘЙЕ ЮК”

3.Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.

4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис Закирова Р.Р.